ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына реабилитацияләнгән гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу һәм исәпне алып бару буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 124-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына реабилитацияләнгән гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу һәм исәпне алып бару буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 124-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 29 октябре
№ 429-VII ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЗАКОНЫ

## Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына реабилитацияләнгән гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу һәм исәпне алып бару буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Сәяси репрессияләр корбаннарын реабилитацияләү турында» 1991 елның 18 октябрендәге 1761-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына (алга таба – җирле үзидарә органнары) реабилитацияләнгән гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу һәм исәпне алып бару буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирә.

2 статья. **Җирле үзидарә органнарына бирелә торган дәүләт вәкаләтләре**

Җирле үзидарә органнарына репрессияләргә бәйле рәвештә торак урыннарын югалткан, «Сәяси репрессияләр корбаннарын реабилитацияләү турында» 1991 елның 18 октябрендәге 1761-1 номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә торак урыннары алуга хокуклы булган реабилитацияләнгән гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларын алар Татарстан Республикасында элеккеге яшәү урынына (репрессиягә эләккәнче яшәгән җирләренә һәм торак пунктларына) кайткан очракта торак урыннарына мохтаҗлар сыйфатында исәпкә алу һәм исәпне алып бару буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре (алга таба — дәүләт вәкаләтләре) бирелә.

3 статья. **Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре бирелә торган муниципаль берәмлекләр исемнәре**

Татарстан Республикасының түбәндәге муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре бирелә:

Казан шәһәре, Чаллы шәһәре, Әгерҗе муниципаль районы, Азнакай муниципаль районы, Аксубай муниципаль районы, Актаныш муниципаль районы, Алексеевск муниципаль районы, Әлки муниципаль районы, Әлмәт муниципаль районы, Апас муниципаль районы, Арча муниципаль районы, Әтнә муниципаль районы, Баулы муниципаль районы, Балтач муниципаль районы, Бөгелмә муниципаль районы, Буа муниципаль районы, Югары Ослан муниципаль районы, Биектау муниципаль районы, Чүпрәле муниципаль районы, Алабуга муниципаль районы, Зәй муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы, Кайбыч муниципаль районы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кукмара муниципаль районы, Лаеш муниципаль районы, Лениногорск муниципаль районы, Мамадыш муниципаль районы, Менделеевск муниципаль районы, Минзәлә муниципаль районы, Мөслим муниципаль районы, Түбән Кама муниципаль районы, Яңа Чишмә муниципаль районы, Нурлат муниципаль районы, Питрәч муниципаль районы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Саба муниципаль районы, Сарман муниципаль районы, Спас муниципаль районы, Тәтеш муниципаль районы, Тукай муниципаль районы, Теләче муниципаль районы, Чирмешән муниципаль районы, Чистай муниципаль районы, Ютазы муниципаль районы.

4 статья. **Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибе**

Җирле үзидарә органнары тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләрен җайга сала торган башка норматив хокукый актлары, шулай ук әлеге Закон нигезендә гамәлгә ашыралар.

5 статья. **Җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре бирелә торган чор**

Җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре чикләнмәгән вакытка бирелә.

6 статья. **Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен финанс белән тәэмин итү**

1. Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрнең гомуми күләме һәм аны муниципаль берәмлекләр арасында бүлү, әлеге Законга кушымта нигезендә,

Репрессияләргә бәйле рәвештә торак урыннарын югалткан реабилитацияләнгән гражданнарны һәм аларның торак урыннарын алуга хокуклы булган гаилә әгъзаларын Татарстан Республикасы территориясендә элеккеге яшәү урынына (репрессиягә эләккәнче яшәгән җирләренә һәм торак пунктларына) кайткан очракта җирле үзидарә органнары тарафыннан торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу һәм исәпне алып бару буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен билгеләү методикасы нигезендә билгеләнә.

3. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.

7 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына түләүсез файдалануга тапшырыла торган мөлкәт**

1. Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт, әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү кирәк булган очракта, җирле үзидарә органнарына тапшырыла торган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен файдалануга һәм (яисә) идарә итүгә тапшырылырга тиешле мөлкәт исемлеге нигезендә җирле үзидарә органнарына түләүсез файдалануга тапшырыла.

2. Җирле үзидарә органнарына тапшырыла торган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен файдалануга һәм (яисә) идарә ителүгә тапшырылырга тиешле мөлкәт исемлеген әзерләү, аны раслау һәм мөлкәтне тапшыру турында карар кабул итү башкарма хакимиятнаң дәүләт сәясәтен үткәрүче һәм торак өлкәсендә идарә итү функцияләрен башкаручы республика органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8 статья. **Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының хокуклары һәм бурычлары**

1. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары хокуклы:

1) тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча үтәлеше мәҗбүри булган норматив хокукый актлар кабул итәргә һәм аларның үтәлешен тикшереп торырга;

2) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру барышында җирле үзидарә органнары яисә аларның вазыйфаи затлары тарафыннан җибәрелгән хокук бозуларны бетерү, шул исәптән әлеге Закон таләпләрен бозуларны бетерү буенча язма күрсәтмәләр бирергә;

3) җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча эшчәнлеген координацияләүне гамәлгә ашырырга;

4) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле документлар, мәгълүмат һәм

материаллар соратып алырга.

2. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тиеш:

1) җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле мөлкәтне һәм финанс чараларын тапшырырга;

2) җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча тәкъдимнәрен карарга;

3) җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын, шулай ук бу максатларга бирелгән финанс чараларыннан файдалануларын тикшереп торырга;

4) җирле үзидарә органнарына аларның соравы буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирергә;

5) җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда консультация, оештыру һәм методик ярдәм күрсәтергә.

### 9 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнарының хокуклары һәм бурычлары**

1. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнары хокуклы:

1) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча актлар чыгарырга;

2) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле эшчәнлекне камилләштерү буенча билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр кертергә;

3) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарында дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча консультация һәм методик ярдәм алырга.

2. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнары тиеш:

1) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җаваплы вазыйфаи затларны билгеләргә;

2) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган мөлкәтне исәпкә алырга һәм аннан тиешенчә файдалануны тәэмин итәргә;

3) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бүлеп бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдаланырга;

4) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру һәм финанс чараларын тоту турында хисаплар тапшырырга;

5) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарына җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын тикшереп торуда кирәкле ярдәм күрсәтергә;

6) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру туктатылган очракта файдаланылмаган финанс чараларын кире кайтарырга.

### 10 статья. **Җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисап бирү тәртибе**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисаплар җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт сәясәтен алып баручы һәм торак өлкәсендә идарә итү функцияләрен гамәлгә ашыручы органына квартал саен, хисап кварталы тәмамланганнан соң 45 көннән дә соңга калмыйча, хисап чорыннан соң килә торган елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча тапшырыла торган дүртенче квартал өчен хисаптан тыш, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән форма буенча тапшырыла.

### 11 статья. **Җирле үзидарә органнарының тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруын тикшереп тору**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору гамәлгә ашырыла:

1) дәүләт сәясәтен үткәрүче һәм торак өлкәсендә идарә итү функцияләрен гамәлгә ашыручы республика башкарма хакимияте органы тарафыннан, тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешенчә гамәлгә ашыру өлешендә, түбәндәге ысуллар белән:

а) дәүләт вәкаләтләрен үтәү турында кирәкле документлар, хисаплар һәм мәгълүмат соратып алулар;

б) «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 41 статьясында каралган тәртиптә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә тикшерүләр үткәрү;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан, дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган финанс чараларыннан максатчан файдалану өлешендә, түбәндәге ысуллар белән:

а) дәүләт вәкаләтләрен үтәү турында кирәкле документлар, хисаплар һәм мәгълүмат соратып алулар;

б) «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 41 статьясында каралган тәртиптә җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру эшчәнлегенә кирәк булган саен тикшерүләр үткәрү;

в) хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча кирәкле чаралар күрү;

3) әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне җирле үзидарә органнарына түләүсез файдалануга тапшырган очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан, дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт мөлкәтен саклау һәм тиешенчә файдалану өлешендә, түбәндәге ысуллар белән:

а) дәүләт вәкаләтләрен үтәү турында кирәкле документлар, хисаплар һәм мәгълүмат соратып алулар;

б) «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 41 статьясында каралган тәртиптә тикшерүләр үткәрү;

в) хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча кирәкле чаралар күрү;

4) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең юстиция өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләре мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актларның Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килүен тәэмин итү өлешендә, түбәндәге ысуллар белән:

а) кирәкле мәгълүматны, муниципаль хокукый актлар проектларын, тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен үтәү өчен җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актларны соратып алулар;

б) муниципаль хокукый актлар проектларына һәм тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен үтәү өчен җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актларга хокукый экспертиза үткәрү һәм анализ ясау.

## 12 статья. **Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату шартлары һәм тәртибе**

1. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату Татарстан Республикасы законы белән түбәндәге очракларга гамәлгә ашырыла:

1) җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен җайга салу өлкәсендәге законнар таләпләрен үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү;

2) җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затларының әлеге Законны бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәне үтәмәүләре;

3) федераль законнарга яисә Татарстан Республикасы законнарына җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен үтәү мөмкин булмаслык үзгәрешләр кертелгәндә;

4) законнарда каралган башка очракларда.

2. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган файдаланылмаган финанс чараларын һәм мөлкәтне кире кайтаруга китерә.

3. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча гамәлдәге законнар таләпләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең торак өлкәсендә, финанс сәясәте өлкәсендә һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органнары, күрсәтелгән хокук бозулар ачыкланган көннән алып 10 көн эчендә җирле үзидарә органнарына аларны бетерү турында күрсәтмә җибәрәләр.

4. Ачыкланган хокук бозуларны бетерү турындагы күрсәтмә җирле үзидарә органына кергән көннән алып ун көннән дә соңга калмыйча мәҗбүри каралырга тиеш. Күрсәтмәне карау нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы башкарма

хакимиятенең торак өлкәсендә, финанс сәясәте өлкәсендә һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органнарына кичекмәстән язма рәвештә хәбәр итәлә.

5. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган очракларда, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең торак өлкәсендә, финанс сәясәте өлкәсендә һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә вәкаләтле органнары җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату турында тәкъдимнәрне һәм тиешле Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карауга кертәләр.

13 статья. **Йомгаклау нигезләмәләре**

1. Әлеге Закон 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары әлеге Закон үз көченә кергән көннән алып өч ай эчендә аңа туры китерелергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Рәисе

«Татарстан Республикасы
муниципаль районнарының
һәм шәһәр округларының
җирле үзидарә органнарына
реабилитацияләнгән гражданнарны
торак урыннарына мохтаҗ буларак
исәпкә алу һәм исәпне алып
бару буенча Татарстан Республикасы
дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

**Репрессияләргә бәйле рәвештә торак урыннарын югалткан реабилитацияләнгән гражданнарны һәм аларның торак урыннарын алуга хокуклы булган гаилә әгъзаларын Татарстан Республикасы территориясендә элеккеге яшәү урынына (репрессиягә эләккәнче яшәгән җирләренә һәм торак пунктларына) кайткан очракта җирле үзидарә органнары тарафыннан торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу һәм исәпне алып бару буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен билгеләү методикасы**

1. Әлеге методика җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен үтәсен өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары (алга таба - муниципаль берәмлекләр) бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен билгеләү өчен каралган.

2. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль берәмлекләр бюджетларга бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләме $C_{общ}$түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$C_{общ} = \sum_{i=1}^{n} C_i ,$$

монда:

$C_i$ – i-муниципаль берәмлек бюджетына бирелә торган субвенция күләме;

n – территорияләрендә вәкаләтләр гамәлгә ашырыла торган муниципаль берәмлекләр саны.

3. i муниципаль берәмлек бюджеты өчен субвенция күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$C_i = Q_{орг_i} \times H_{орг_i} ,$$

монда:

$Q_{орг_i}$ – i муниципаль берәмлектә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең норматив саны;

$H_{орг_i}$ – -i-муниципаль берәмлектә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бер хезмәткәргә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар.

4. i муниципаль берәмлектә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең норматив саны түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Q_{\text{орг}_i} = \text{Кгр}_i \times \text{Торг}_i \,/\, (8 \times 240{,}5),$$

монда:

К $\text{гр}_i$ – репрессияләргә бәйле рәвештә торак урыннарын югалткан реабилитацияләнгән гражданнар һәм аларның торак урыннарын алуга хокуклы булган гаилә әгъзалары саны (алга таба - реабилитацияләнгән гражданнар), Татарстан Республикасы территориясендә элеккеге яшәү урынына (репрессиягә эләккәнче яшәгән җирләренә һәм торак пунктларына) кайткан очракта, i-муниципаль берәмлектә шартлы рәвештә бер;

$\text{Торг}_i$ – i муниципаль берәмлектә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бер хезмәткәрнең реабилитацияләнгән бер гражданны исәпкә алу һәм исәпне алып бару буенча эш нормативы күрсәткече, 8 эш сәгатенә тигез;

8 – көнгә эш сәгатьләре саны;

240,5 – елына эш көннәре саны (ял, бәйрәм көннәрен исәпкә алып, 5 көнлек эш атнасында).

5. i муниципаль берәмлектә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бер хезмәткәргә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарны исәпләү түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$H_{\text{орг}_i} = (\text{З}_{\text{от}_i} + H_{\text{з}_i}) \times 12,$$

монда:

$\text{З}_{\text{от}_i}$ – i муниципаль берәмлектә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бер хезмәткәрнең хезмәте өчен түләүгә норматив чыгымнар;

$H_{\text{з}_i}$ – i-муниципаль берәмлектә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бер хезмәткәрнең хезмәтенә түләү буенча түләүләргә исәпләнгән чыгымнар.

6. i муниципаль берәмлектә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бер хезмәткәрнең хезмәте өчен түләүгә норматив чыгымнар «баш белгеч» вазыйфасы буенча Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнә.

7. Агымдагы финанс елына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләме һәм i-муниципаль берәмлек бюджетына агымдагы финанс елына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бирелә торган субвенция күләме әлеге Методиканың 4 пунктындагы дүртенче абзацында билгеләнгән күрсәткечнең агымдагы финанс елының 1 ноябренә торышы буенча фактгагы күрсәткечләреннән чыгып үзгәртелергә мөмкин.

Агымдагы финанс елына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен билгеләү һәм агымдагы финанс елына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга i-муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган субвенцияләр күләмен, әлеге пункт нигезләмәләрен исәпкә алып, исәпләп чыгару әлеге Методиканың 2-6 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

**«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына реабилитацияләнгән гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу һәм исәпне алып бару буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына реабилитацияләнгән гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу һәм исәпне алып бару буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы закон пректы «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба – 63-ТРЗ номерлы Закон) 6 статьясындагы 2 пунктын гамәлгә ашыру максатыннан эшләнгән.

63-ТРЗ номерлы Законның югарыда күрсәтелгән нормасы нигезендә (2025 елның 25 апрелендәге 25-ТРЗ номерлы Закон редакциясендә) репрессияләргә бәйле рәвештә торак урыннарын югалткан реабилитацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары Татарстан Республикасы территориясендә элеккеге яшәү урынына (репрессиягә эләккәнче яшәгән җирләренә һәм торак пунктларына) кайткан очракта торак урыннарына мохтаҗ дип танылалар. Күрсәтелгән затлар исәпкә алыналар һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә торак урыннары белән тәэмин ителәләр. Бу хокук шулай ук алар репрессиягә эләккәнче репрессияләнгән затлар белән бергә яшәгән гаилә әгъзаларына һәм башка туганнарына, шулай ук иректән мәхрүм итү урыннарында, сөргендә, махсус поселениедә туган балаларга да кагыла.

Реабилитацияләнгән затларны торак урыннары белән тәэмин итү аларга социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү юлы белән гамәлгә ашырылачак. Җирле үзидарә органнарына социаль наем шартнамәсе буенча әлеге гражданнарны торак урыннары белән тәэмин итү максатларында исәпкә алу һәм исәпне алып бару буенча дәүләт вәкаләтләрен бирү өчен җирле үзидарә органнарына тиешле вәкаләтләр бирү турында Татарстан Республикасы законын кабул итү таләп ителә.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, карала торган Татарстан Республикасы законы проектында җирле үзидарә органнарына югарыда күрсәтелгән гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу һәм исәпне алып бару буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына реабилитацияләнгән гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу һәм исәпне алып бару буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына реабилитацияләнгән гражданнарны торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алу һәм исәпне алып бару буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.